| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**03.07.2026** | **Зеленодольск**<br>**шәһәре** | **КАРАР**<br>**№ 2323** |

ЗМР БК 2014 елның 15 маендагы 940 номерлы карары белән расланган (2020 елның 28 августындагы 1590 номерлы, 2021 елның 12 февралендәге 266 номерлы карарларындагы үзгәрешләрне кертеп), Зеленодольск муниципаль районы мәгариф оешмалары укучыларына һәм укытучыларына фән олимпиадаларында катнашу йомгаклары буенча һәм мәгариф оешмаларын тәмамлаучыларның бердәм дәүләт имтиханы формасында дәүләт йомгаклау аттестациясен узу йомгаклары буенча грант ярдәме күрсәтү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законның 1 өлешендәге 26 пункты һәм 34 статьясындагы 2 өлешенең 5 һәм 7 пунктлары нигезендә, гомуми белем бирү фәннәреннән Республика фән олимпиадаларыннан, Бөтенроссия олимпиадаларының муниципаль, региональ һәм Бөтенроссия этаплары җиңүче һәм призер укучыларны , бердәм дәүләт имтиханы формасында дәүләт йомгаклау аттестациясен узу йомгаклары буенча белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларны, шулай ук гомуми белем бирү предметлары буенча Республика фән олимпиадаларыннан, Бөтенроссия олимпиадаларының муниципаль, региональ һәм Бөтенроссия этапларында катнашу йомгаклары буенча гомуми белем бирү оешмалары укытучыларын кызыксындыру максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. ЗМР БК 2014 елның 15 маендагы 940 номерлы карары белән расланган (2020 елның 28 августындагы 1590 номерлы, 2021 елның 12 февралендәге 266 номерлы карарлардагы үзгәрешләрне кертеп), Зеленодольск муниципаль районы мәгариф оешмалары укучыларына һәм укытучыларына фән олимпиадаларында катнашу йомгаклары буенча һәм мәгариф оешмаларын тәмамлаучыларның бердәм дәүләт имтиханы формасында дәүләт йомгаклау аттестациясен узу йомгаклары буенча грант ярдәме күрсәтү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.4 пунктына түбәндәге абзацны өстәргә:

«2026 елда Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы бердәм дәүләт имтиханы йомгаклары буенча 100 балл җыйган чыгарылыш сыйныф укучысына бер тапкыр бирелә торган 100 мең сум акчалата бүләк рәвешендә грант гамәлгә кертә. Берничә фәннән бердәм дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 балл җыйган укучыга грант һәр фән өчен 100әр мең сум итеп бирелә».

2. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигына массакүләм мәгълүмат чараларында, Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җитәкче урынбасары – Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин